Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» гамәлдәге муниципаль бюджет учреждениесе тибын үзгәртү турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының 44 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елның 01 сентябреннән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Централизованная бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесе тибын Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Централизованная бухгалтерия» муниципаль казна учреждениесе төзү максатларында үзгәртү.

2. Әлеге карар кабул ителгән көнгә гамәлдә булган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесенең барлык хокуклары һәм бурычлары буенча хокукый варисы булып тора, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» Муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлегенең төп максатларын Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль казна учреждениесе өчен сакларга.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Централизованная бухгалтерия» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе ( Р.Р. Хамдеева):

учреждениенең төре үзгәрүгә һәм муниципаль хокукый актларга тиешле үзгәрешләргә бәйле рәвештә муниципаль бюджет учреждениесенең гамәлгә кую документларына тиешле үзгәрешләр кертүне 2017 елның 01 сентябренә кадәр тәэмин итәргә;

штат санын сакларга;

2017 елның октябренә кадәр муниципаль казна учреждениесенең бюджет сметасын район бюджетына чыгымнар кертү максатыннан исәпләргә.

5. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының “Үзәкләштерелгән бухгалтерия” муниципаль бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәтне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының “Үзәкләштерелгән бухгалтерия” муниципаль казна учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетергә.

6. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының финанс-бюджет палатасы:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан акчалар алучылар, баш күрсәтмәчеләр, акчалар алучылар реестрына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының “Үзәкләштерелгән бухгалтерия” муниципаль казна учреждениесе турында, юридик затларның бердәм дәүләт реестрын яздыру кәгазьләрен алганнан соң, белешмәләр кертергә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районыннан бюджет сметасы нигезендә муниципаль казна учреждениесен финанс белән тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарны «Туган як» газетасында бастырырга.

8. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

9. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Е.А. Тарнавскийга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ш.А. Алиуллов